КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 14 ноябрь г.Казань № 1003

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 25 сентябрь, 830 нчы карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 25 сентябрь, 830 нчы карарына, VII бүлекнең 7.6 пунктындагы 18 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«18 нче таблица

Һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү буенча төркеме, база оклады күләмнәре һәм җитәкчегә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимул бирү характерындагы түләүләр

| Җитәкченең хезмәт өчен түләү буенча төркеме | Дәүләт биреме нигезендә күләм күрсәткеченең зурлыгы (уку елы башына карата белем алучылар саны), кеше* | База окладı, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимул бирү характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | 0 – 500 | 42 000 | 11 000 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2 | 501 – 900 | 46 000 | 11 000 |
| 3 | 901 – 1 300 | 49 000 | 13 000 |
| 4 | 1 301 – 2 000 | 50 000 | 17 000 |
| 5 | 2 001 – аннан да югарырак | 51 000 | 20 000 |

---

[*]Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларында (олимпия резервы училищесы) укучылар, спорт осталыгын һәм югары спорт осталыгын камилләштерү этапларында белем алучылар контингенты 3 коэффициент белән исәпкә алына.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин